Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Иске Салман авыл җирлегенең Иске Такталы авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 26 ноябре 2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 19 номерлы Әлки муниципаль районының «Иске Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 17 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлегенең Иске Такталы авылында гражданнар җыенының 2019 елның 26 ноябрендәге 3 номерлы йомгаклау беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге составына керүче Иске Такталы авылында гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, Чернобыль АЭС нәтиҗәләрен бетерүдә һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертү турында Карар кабул итүне таныргa.

Алардан:

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге торак пунктларында урамнарны яктыртуны ремонтлау һәм техник тәэмин итү, урам утларын кулланган өчен чыгымнарны түләү һәм материал сатып алуга -100 сум;

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге торак пунктларында суэтем башнясы территориясен коймалап алу, суэтем башняларын буяу, урамнарны су белән тәэмин итү системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау, инвентарь һәм материал сатып алуга -195 сум;

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге торак пунктларында урам юлларын төзекләндерү һәм ремонтлау, кышын урам юлларын кардан чистарту өчен -220 сум.

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге торак пунктларында каты көнкүреш калдыклары өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә һәм контейнерлар сатып алуга бәйле чыгымнар, белгечләр эше өчен килешү буенча түләүгә -85 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

**2.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, моннан тыш, 1 Төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, Чернобыль АЭС нәтиҗәләрен бетерүдә һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар, көндезге формада укучы студентлардан тыш алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

алардан:

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге торак пунктларында урамнарны яктыртуны ремонтлау һәм техник тәэмин итүгә, урам утларын кулланган өчен чыгымнарны түләүгә һәм материал сатып алуга -100 сум

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге торак пунктларында суэтем башнясы территориясен коймалап алу, суэтем башняларын буяу, урамнарны су белән тәэмин итү системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау, инвентарь һәм материал сатып алуга -195 сум;

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге торак пунктларында урам юлларын реконструкцияләү һәм ремонтлау, кышын урам юлларын кардан чистартуга -220 сум;

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге торак пунктларында каты көнкүреш калдыклары өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә һәм контейнерлар сатып алуга бәйле чыгымнар, белгечләр эше өчен килешү буенча түләүгә -85 сум.

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Салман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.http://pravo.tatarstan/

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Иске Салман авыл җирлеге җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы: А.Р.Халиуллин